# Нурчуклар

*Буа районы “Кояшкай” балалар бакчасы гәҗите*

**№3 Ноябрь, 2021 ел**


## ТАТАР МАЛАЕ, ТАТАР КЫЗЫ - 2020



Район балалар бакчаларында тәрбияләнүче балалар арасында «Татар малае, татар кызы-2020» бәйгесе булып узды. Бәйгенең куст этабында "Кояшкай" балалар бакчасында тәрбияләнүче Фаткуллов Самат, Сиразева Руфина катнаштылар. Ярышта алар үзләренең осталыкларын күрсәттеләр. "Таныш булыйк" өлешендә үзләре белән таныштырдылар. ТАССРның 100еллыгына багышлап иҗади номер күрсәттеләр һәм татар халкына багышланган кул эшләре тәкьдим иттеләр.

Район этабына чыккан Сиразева Руфина "Татар кызы-2020" исеменә лаек булды. Ул үзендә чын татар кызларына гына хас күркәмлек, осталык, иҗади сәләтен күрсәтте. Руфинабыз кебек татар җанлы балалар илебезнең күрке булып үсәрләр.

## Бүгенге санда


1.“Татар малае, татар кызы-2020” җиңүчеләре

2. Бакчабызда “Әниләр бәйрәме”

3. Төрлесеннән




### *Хөрмәтле әниләребез!*

Бәйрәм уңаеннан чын күңелдән чыккан котлау сүзләрен кабул итеп алыгыз.

Безнең һәрберебез өчен җир йөзендә әнидән дә якын кеше юк. Ул бетмәс-төкәнмәс шәфкатьлек, күңел юмартлыгын һәм мәхәббәтне гәүдәләндерә. Аның кайгыртуы һәм игътибарын гомер буена тоябыз. авыр вакытларда ярдәм сорап без нәкъ менә аңа мөрәҗәгать итәбез, аңа сыенабыз. Балаларның физик һәм әхлакый сәламәтлеге, димәк, имин киләчәгебез әниләрнең нәфис кулында. Сез гаилә традицияләрен, җәмгыятебезнең әхлакый һәм мәдәни кыйммәтләрен саклаучы. Һәр әни балалар сау-сәламәт, уңышлы, үз иленең чын гражданы булып үссен өчен күп көч һәм сабырлык куя. Сез үзегезне ышанычлы һәм саклаган итеп тойсын өчен барлык шартларны булдыру җирле үзидарә органнарыннан алып хакимиятнең барлык дәрәҗәләре бурычы. Иң мөһиме - бала үсеп, өлкәнәйгәч тә ана мәхәббәтен гомерлеккә сакласын.

Кадерле әниләребез, зур мәхәббәтегез, безне аңлавыгыз һәм сабырлыгыгыз өчен зур рәхмәт сезгә. Чын күңелдән сезгә бәйрәмне яраткан гаиләгез белән каршы алуыгызны, якыннарыгызның хөрмәтен һәм кайгыртуын тоюыгызны, бәхет, сәламәтлек, тынычлык һәм иминлек телибез! Якыннарыгыз бары тик шатлык кына китерсен, сез биргән ярату өчләтә үзегезгә әйләнеп кайтсын.

*Иң изге теләкләр белән Э.З.Абузәрова*

# ҺӘРВАКЫТ БУЛСЫН ӘНИ! ПУСТЬ ВСЕГДА БУДЕТ МАМА!







***Ана! Әни! Нинди бөек исем! Дөньяда әниләрдән дә газиз, изге зат юктыр. Әлеге кыска гына сүз үзендә күпме наз, йөрәк җылысы һәм яратуны саклый. “Кояшкай” балалар бакчасында тәрбияләнүчеләр әниләрен бәйрәм белән котладылар.***





## Большая и малая родина



Патриотическое воспитание ребенка является основой формирования личности будущего гражданина. С этой целью в средней группе "Радуга" воспитателем Комиссаровой Н.В. было проведено занятие по окружающему миру "Большая и малая Родина". На протяжении всего занятия у детей формировались такие важные понятия,как любовь к родному краю, уважение к старшим, к традициям своей малой Родины.

## STAR-БУА

"Кнопочки" вокаль коллективын уңышлы чыгышлары белән котлыйбыз. Алар "STAR-БУА" балалар һәм яшүсмерләр иҗаты республика конкурсында 1 дәрәҗә лауреат булдылар. Алга таба да уңышлар телибез!!!



## Зоопаркта

Бүген безнең балалар бакчасында уеннар атнасы кысаларында сюжетлы-рольле уен карау булып узды. Мәктәпкә әзерлек төркеме балалары, тәрбияче Әхмәтҗанова А.А. белән бергә "Зоопарк"ка бардылар. Балалар уен барышында махсус атрибутлар кулланып, сюжет уйлап таптылар,. Шулай ук диалог төзергә, уен сюжеты нигезендә үз рольләрен кулланырга өйрәнделәр. Балаларны уйнарга , аларның тормышына уенны кертергә өйрәтү-безнең педагогларның төп бурычы.





# Минем әнием...






Ана -
Бөек исем,
Нәрсә җитә ана булуга;
Хатыннарның бөтен
матурлыгы,
Бөтен күрке – ана
булуда.   һ.Такташ





# Төсле кроссворд

ДУСКАЙ, СИН БИРЕДӘ НИЛӘР КҮРӘСЕҢ? АТАМАЛАРНЫ ШАКМАКЛАРГА ДӨРЕС ИТЕП ЯЗ.





«Нурчыклар» гәҗитен гамәлгә куючы: Татарстан Республикасы Буа шәһәренең катнаш төрдәге “Кояшкай” балалар бакчасы” муниципаль бюджет учреждениесе

Редколлегия әгъзалары: Гиниятуллина Д.Р. Шакирова Г.Р



Безнең адрес:
422430, Буа шәһәре,
Арефьева урамы, 13 йорт

Тел. (843)743-13-09
E-mail: colnush-bua@mail.ru